ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы, 422586

Тел.: (84379) 35-5-70, факс: (84379) 35-5-70.

13.12.2025 01

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 №33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, түбәндәге гражданнар категорияләреннән тыш, һәр балигъ булган кешедән үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә:

а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары
б) контрактчылар
в) вакытлы хезмәт солдатлары
Аерым категория гражданнар өчен:
а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар
б) 1 төркем инвалидлар,
в) уку йортлары студентлары
г) күпбалалы гаиләләр
түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
Патрикеево торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

3. Бу карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Җыелышта рәислек итүче: Д.В.Плохов